ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 3** **31 января 2023года**

2023 елга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының «Димтамак
авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү хезмәтләренең гарантияле исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гы 57 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында"гы 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советыңд 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Димтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. 2023 елның 1 февраленнән Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендә 7793,48 (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) суммасында билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»гы 9 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Бердәм порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ. Ә. Хөснетдинов

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге
Башкарма комитетының

2023 елның “31 ”гыйнварындагы
3 санлы карарына
1 кушымта

2023 елның 1 февраленнән күмү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумга) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җибәрү | 3115,52 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (калдыкларын) алып бару | 952,3 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге
Башкарма комитетының

2023 елның “31 ”гыйнварындагы
3 санлы карарына
2 кушымта

2023 елның 1 фераленнән күмү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 723,02 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җибәрү | 2392,5 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (калдыкларын) алып бару | 952,3 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |